**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БӘТКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

03.04.2017 ел № 3/1

КАРАР

«2016 ел өчен Бәтке авыл җирлеге бюджеты
үтәлеше турында» хисап проекты хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законга, Бәтке авыл җирлеге Уставына таянып, шулай ук Бәтке авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе М. А. Ионычевның «Бәтке авыл җирлегенең 2016 елгы бюджеты үтәлеше турында хисап проекты» хакында мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2016 ел өчен Бәтке авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисап проектын 1 кушымта нигезендә расларга.
2. «2016 ел өчен Бәтке авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисап проекты турында» әлеге карарны Бәтке авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырып халыкка игълан итергә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Советның бюджет, салымнар, финанслар һәм икътисад буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Бәтке авыл җирлеге Башлыгы М.А. Ионычев